КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 декабрь г.Казань № 1599

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 18 май, 461 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 19 октябрь, 1323 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1.1 пунктның таблицасында:

10 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Амбулаториядәге авырган кешеләрнең медицина картасыннан туберкулезга тикшерү нәтиҗәләре, эчәк инфекциясе кузгатучылар төркеменә, гельминт йомыркасына, дифтериягә, җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә (сифилис,

гонорея, ВИЧ-инфекция) лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре, профилактика прививкалары турында белешмә бирелгән өземтә»;

12 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасына кергәнгә кадәр 21 календарь көн эчендә яшәү урыны буенча йогышлы авырулар белән контактлар булмау турында белешмә кәгазе»;

3.1.1 пунктның таблицасында:

10 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Амбулаториядәге авырган кешеләрнең медицина картасыннан туберкулезга тикшерү нәтиҗәләре, эчәк инфекциясе кузгатучылар төркеменә, гельминт йомыркасына, дифтериягә, җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә (сифилис, гонорея, ВИЧ-инфекция) лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре, профилактика прививкалары турында белешмә бирелгән өземтә»;

12 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасына кергәнгә кадәр 21 календарь көн эчендә яшәү урыны буенча йогышлы авырулар белән контактлар булмау турында белешмә кәгазе»;

2.1.1 пунктның таблицасында:

10 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Амбулаториядәге авырган кешеләрнең медицина картасыннан туберкулезга тикшерү нәтиҗәләре, эчәк инфекциясе кузгатучылар төркеменә, гельминт йомыркасына, дифтериягә, җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә (сифилис, гонорея, ВИЧ-инфекция) лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре, профилактика прививкалары турында белешмә бирелгән өземтә»;

12 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасына кергәнгә кадәр 21 календарь көн эчендә яшәү урыны буенча йогышлы авырулар белән контактлар булмау турында белешмә кәгазе»;

5.1.2 пунктның беренче абзацында «7 яшькә кадәрге инвалид балалар» сүзләрен «7 яшькә кадәрге сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалид балалар» сүзләренә алмаштырырга;

5.4.1 пунктта «(инвалид балалар)» сүзләрен «(сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалид балалар)» сүзләренә алмаштырырга;

5.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.2. Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә күрсәтелә:

социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә – даими булышлык күрсәтеп торуга мохтаҗ инвалидларга, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткән гражданнарга;

инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – инвалидларга;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә – инвалид балаларга; 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәр сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга;

Социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең

эш көннәрендә исәпләнә һәм инвалид балалар, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар өчен – 21 эш көненә кадәр, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар өчен – 15 эш көне, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен – 15 эш көне тәшкил итәргә тиеш.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү ешлыгы елына 2 тапкыр; инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә ике елга 1 тапкыр тәшкил итә. Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә буш урыннар булганда (чират булмаганда) инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге елына 1 тапкыр бирелә.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар, инвалид балалар өчен стационар формада социаль хезмәт күрсәтү срогы инвалидның (аның законлы вәкиленең), инвалид баланың законлы вәкиленең социаль хезмәт күрсәтү срогы тәмамланганга кадәр социаль хезмәтләр күрсәтүченең эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча бирелгән тиешле гаризасы нигезендә (социаль хезмәтләр күрсәтүченең эш көннәрендә исәпләнә торган иң күбе 30 көнгә) озайтыла.

Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар социаль хезмәтләрдән файдаланучының мотивацион әзерлеге (тернәкләндерү дәресләрендә даими булу, тәкъдимнәрне үтәү) һәм тернәкләндерү чараларын уздыру нәтиҗәсендә уңай динамикасы булганда кимендә социаль хезмәтләр күрсәтү срогы тәмамлану көненә кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган кимендә өч көн кала кабул ителә. Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында кабул ителгән карар хакында социаль хезмәтләрдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы (аның законлы вәкиле) белән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү төзи, ул социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында кабул ителгән карар нигезендә озайтыла.»;

6.1.1 пунктның таблицасына түбәндәге эчтәлекле 2 һәм 3 пунктлар өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Амбулаториядәге авырган кешеләрнең медицина картасыннан туберкулезга тикшерү нәтиҗәләре, эчәк инфекциясе кузгатучылар төркеменә, гельминт йомыркасына, дифтериягә, җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә (сифилис, гонорея, ВИЧ-инфекция) лаборатория тикшеренүләре | медицина оешмалары | законнар нигезендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нәтиҗәләре, профилактика прививкалары турында белешмә бирелгән өземтә | | |
| 3. | Социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасына кергәнгә кадәр 21 календарь көн эчендә яшәү урыны буенча йогышлы авырулар белән контактлар булмау турында белешмә кәгазе | медицина оешмалары | 3 көн; |

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасындагы «Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә I төркем инвалидларга, 7 яшькә кадәрге инвалид балаларга, өченче дәрәҗә чагылыш тапкан теләсә кайсы категориядәге инвалид балаларга даими ярдәм күрсәтеп торучыларга (алга таба – даими ярдәм күрсәтеп торучылар) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә хезмәтләр күрсәтү исеме, тасвирламасы, күләме» таблицасы исемендәге «7 яшькә кадәрге инвалид балаларга» сүзләрен «сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, 7 яшькә кадәрге инвалид балаларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипнең 4[1] нче кушымтасындагы таблицаның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «1.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү, шул исәптән: | социаль хезмәтләр күрсәтү өчен (1 социаль хезмәтләр күрсәтелүчегә) санитария-гигиена таләпләренә туры килә торган мәйданнар бирү | кв.метр | 18 | социаль хезмәт күрсәтү чорында |
| 1.1.1. | торак мәйданы бирү: инвалидларны тернәкләндерү үзәгендә 1 социаль хезмәтләр күрсәтелүчегә | зурлыгы һәм башка тормыш күрсәткечләре буенча торак мәйданы (бүлмәнең торышы һәм уңайлылыгы) санитария-гигиена нормаларына туры килергә һәм клиентларның яшәү уңайлыгын тәэмин итәргә тиеш | кв.метр | 6 | социаль хезмәт күрсәтү чорында». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче; 2020 ел, 6 июль, 555 нче; 2021 ел, 21 апрель, 268 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2022 ел, 12 декабрь, 1316 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1493 нче; 2023 ел, 1 март, 195 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 13 июль, 823 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 23 август, 1003 нче; 2023 ел, 31 август, 1054 нче; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1293 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә, 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.4.2. Социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә күрсәтелә:

социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә – даими булышлык күрсәтеп торуга мохтаҗ инвалидларга, «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткән гражданнарга;

инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә – инвалидларга;

мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә – инвалид балаларга; 0 яшьтән алып 3 яшькә кадәр сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балаларга;

Социаль хезмәтләр күрсәтү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә һәм инвалид балалар, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар өчен – 21 эш көненә кадәр, социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар өчен – 15 эш көне, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен – 15 эш көне тәшкил итәргә тиеш.

Социаль-тернәкләндерү бүлекләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән тыш) вакыты елына ике тапкыр тәшкил итә.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә инвалидлар өчен, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә инвалид балалар, психик бозылышы булган һәм тәртибе бозылган, аралашучанлыгы, социаль бәйләнеше бозылган, инвалидлыгы булмаган, сәламәтлегенең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен социаль хезмәт күрсәтү (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең иртә ярдәм күрсәтү һәм көндезге бүлекләрендә социаль хезмәтләр күрсәтүдән тыш) социаль хезмәт күрсәтү срогы

тәмамлануга кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча бирелгән социаль хезмәтләрдән файдаланучының (аның законлы вәкиленең) тиешле гаризасы нигезендә (әмма социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган иң күбе 30 көнгә) озайтыла.

Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар социаль хезмәтләрдән файдаланучының мотивацион әзерлеге (терпәкләндерү дәресләрендә даими булу, тәкъдимнәрне үтәү) һәм тернәкләндерү чараларын уздыру нәтиҗәсендә уңай динамикасы булганда кимендә социаль хезмәтләр күрсәтү срогы тәмамлану көненә кадәр социаль хезмәтләр белән тәэмин итүченең эш көннәрендә исәпләнә торган кимендә өч көн кала кабул ителә. Социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында кабул ителгән карар хакында социаль хезмәтләрдән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтү срогын озайту турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче социаль хезмәтләр күрсәтүнең соңгы көнендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы (аның законлы вәкиле) белән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәгә өстәмә килешү төзи, ул социаль хезмәт күрсәтү вакытын озайту турында кабул ителгән карар нигезендә озайтыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин